# ҖАН АВАЗЫ

«Казан утлары» журналының 1988 елгы 4–6 нчы саннарында Ибраһим Салаховның «Тайгак кичү» исеме белән басылган һәм киң катлау укучылар тарафыннан хуплап каршыланган әлеге әсәре, авторның йөз аклыгы булу белән бергә, татар халкының горурлыгы да, казанышы да. Утыз җиденче, аннан соңгырак елларда Сталинның үлем чалгысы татар мәдәнияте, әдәбияты вәкилләрен дә кыеп үтә. Күпме асыл ирләр, революция солдатлары һәлак була. Культ корбаны булган язучыларны санап бетерерлек түгел, аларның исемнәре, торган саен, яшәгән саен, якты нур белән өртелә бара. Ибраһим Салахов – шул якты төркемнән исән калган бердәнбер олпат аксакалыбыз. Үзе яшәгән заманны аңларга тырышып, үзе күргән вакыйгаларга гадел бәя биреп, үзенең юлдашларына бөек һәйкәл корып, шушы әсәрен иҗат иткән. Эчтәлеге ягыннан гаять үзенчәлекле, документаль төгәллек белән язылган бу әсәр – Сталин чорының роман-хроникасы да, илебез халыкларының тирән фаҗигасе дә. Шуның белән бергә, бик күп миллионнар арасыннан могҗиза белән генә исән калган Ибраһим ага Салаховның җан авазы да.

Бу китап сез моңарчы укыганнарның берсенә дә охшамаган. Ибраһим Салахов шактый гомерен шушы әсәрне язуга багышлаган. Автор үзе бу әсәрен бер сүз белән генә «Фаҗига» дип атау ягында тора. Болай дип атау – гадел, дөрес бәя! Мәгәр бу шомлы сүз генә әсәрнең бөтен тукымасын, бәян ителгән гадәттән тыш вакыйгаларны үзенә сыйдырып бетерә алмый. Әсәр формасы белән дә, эчтәлеге белән дә моңарчы без белгән әдәби калыпларга сыймый, аңа үзгә бәя, яңа үлчәү кирәк.

Белорус язучысы Василь Быков бервакыт: «Рус һәм башка әдәбиятларда моңарчы басыла алмаган, зама-

ныбызның каршылыклы чорын реалистик тасвирлаган әсәрләр дөнья күрә башлагач, сөрсегән обывательләребездән берәү: «Шөкер, безнең әдәбиятта сандыкта качып яткан әсәрләребез юк!» — дип чыгыш ясады», — дип, йөрәк әрнүен уртаклашкан иде. Милләтебезнең кайбер «акыл ияләре» арасыннан да, ашыгып-ашыгып: «Татарда кайчандыр язылып та басылмый калган әсәрләр юк!» — дип белдерүчеләр булмады түгел, булды, әмма татар әдипләренең учагында ут сүнмәгән икән. Кайберәүләр әзер лозунгларга иллюстрацияләр язып, чиндәрәҗәләр, бүләкләр алырга ашкынып, комсызланып, заманның зарарлы кешеләренә яраклашырга тырышып ал буяуга манылган ялган әсәрләрне бер-бер артлы бастыра торганда, кемдер намус кушканны эшләгән: басылмасын белгән хәлдә, өметсезлеккә бирелмәгән, иҗат иткән, үз сүзен әйтеп калдырырга тырышкан. Шуның иң гыйбрәтле, иң уңышлы мисалы — Ибраһим Салаховның әлеге китабы.

Әсәрдә канлы тиран Сталин үзе күренми. Әсәр дәвамында хаксыз рәвештә җәбер-җәфаларга дучар ителгән бәхетсезләр аның исемен өмет белән яд итәләр. Ул чорның иң тирән каршылыгы да шунда инде әнә! Сталин әсәрдә үзе күренмәсә дә, күзәтүчән, ачык зиһенле Ибраһим Салахов аның портретын төгәл вакыйгалар белән ачып бирә алган.

Сугышка кадәр укылган бер китап хәтеремә үтә нык сеңеп калган. Атаклы немец антифашисты Вилли Бредельның «Сыналу» дигән романы иде ул. Кеше рухын сыту, изү остасы, палач Гитлер үзенә каршы чыккан коммунистлардан үч ала, күп санлы гаепсезләр белән рәттән, асылда, үз дошманнарын җәзалый, кыра. Сталин, үзен Ленинның дәвамчысы дип игълан итеп, иң беренче нәүбәттә Ленин гвардиясен, революциянең тугры солдатларын, совет властеның аңлы, алдынгы вәкилләрен дулкын-дулкын кисеп, таптап үтә, нәселтокымнарын харап итә, аларның балаларын, туганнарын, танышларын, хезмәттәшләрен тормыштан алып ташлый. Мең һәм миллионлаган көрәшчеләрне эзсез юк итә.

Дөрес, бу фактларны, бу тарихи дөреслекне ул чакта күпләр бөтен тулылыгы белән аңлап бетерә алмаган.

Сталин режимының канлы нәтиҗәләрен без партиянең XX съездыннан соң гына күз алдына китерә башладык. Шулай да бу әсәр тарихи дөреслеге, чынлыгы белән шушы характердагы әсәрләр арасында аерым бер урын тота, чөнки аның авторы үзе күргәннәрне, үзе татыганнарны, үзе кичергәннәрне яза. Бу әсәрдә татар халкының бик күп газиз балалары якты сүз белән телгә алына: Хәсән Туфан, Мохтар Мутин, Сөббух Рәфыйков... Тагын бик күп, бик күп язмышлар, кыскакыска гына эпизодларда күренеп китсәләр дә, хәтердә уелып калырлык дәрәҗәдә язылганнар. Төрле катлау, төрле милләт вәкилләре иң авыр елларда да, иң читен юлларда да горур башларын түбән имиләр, сатмыйлар, сатылмыйлар, хыянәткә бармыйлар, туганнарча бер-берсен олылап, бер-берсенә рух өстәп, чын патриотларча төрмә-каторга сиратын кичәләр. Әсәрнең һәр сәхифәсеннән, һәр юлыннан батырлык, кыюлык, гаделлек бөркелеп тора.

КПССның XIX Бөтенсоюз конференциясендә Ватаныбыз башкаласы Мәскәүдә хаксызга җәзаланган ил уллары хөрмәтенә һәйкәл салырга дигән карар кабул ителде. Ибраһим ага Салахов үзенең әлеге китабы белән шул мәгърур һәйкәлнең нигез ташын салучыларның берсе булып саналачак.

***Аяз Гыйләҗев,***
*Татарстан Республикасының*
*халык язучысы*

Тыштан солдат,
Ә эченнән җәллад,
Күрәгендә агу һәм мәкер;
Ул йөрәкне күрсә, Нерон чирканыр,
Торквемада кәфенен бөркәнер.

# ЮЛ БАШЫ

## 1

Институтның тулай торагыннан чыкканда, таң атып, кояш инде күтәрелә дә башлаган иде. Гадәттә, мондый көзге иртәләрдә Казан өстенә Иделне каплаган куе томан сарыла, көн җылынып беткәнче, шәһәр шуннан арына алмый — ак чыбылдык астында кала иде.

Бүген ул томан да юк — күк йөзе күм-күк. Көнчыгыштан көлтә-көлтә алтын нурлар сибелә. Көн җылы, матур булыр, ахрысы. Иртәнге салкын һәм дымсулык, мөгаен, кичәге яңгырның сулышы гынадыр. Гаҗәп! Югыйсә инде «әбиләр чуагы» узганга да айдан артык. Бүген октябрьнең егерме бише бит инде. Бәйрәмгә дә ерак калмады — ике атнадан да ким. Быелгы бәйрәм аеруча тантаналы, күңелле булыр — Бөек Октябрьгә егерме яшь тулачак.

Безнең институт колоннасын бәйрәм демонстрациясенә алып чыгуны ректор быел да миңа тапшырды. Ни генә әйтмә, командир кисәге бит мин. Институтка килеп кергәндә, шинель петлицаларымда чия кызыл өчпочмаклар яна иде... Әле дә өстән хәрби мундир төшми. Ләкин студентларның әзерлеге ташка үлчим, инде ике тапкыр җыелдык — саф дигәннең исе дә юк, сыер көтүе кебек, беребез алда, икенчебез артта. Бигрәк тә кызлар шырык-шырык көлеп теңкәгә тия. Кычкыра-кычкыра тамагым карлыгып бетте. Ай-һай, бу хәтле дә йөгәнсез булыр икән хатын-кыз дигән халык!

Дөресен әйткәндә, әле кайсы факультет артыннан кайсы барасы да ачыкланмаган. Беренче җыелуда та-

рих факультеты алда иде. Икенчесендә, маршировка вакытында, ректор минем планны бозды да ташлады. «Алдан биофак барсын. Анда кызлар күп, чәчәкләр белән чыгарлар», — дип, бер көтү йөгәнсез кызны колоннаның алдына бастырды. Ачуымнан шартларга җитештем, чак-чак кына ректорны сүгеп ташламадым — тешләремне кысып калдым.

Ә менә кичә төнлә үзен, ректорны әйтәм, кулга алганнар, халык дошманы булган, ди. Кем белә, булса булгандыр, революциягә хәтле чит илдә укып кайткан зыялы бит. Болай үзе бик Совет яклы булып сөйли иде. Кем әйтмешли, кеше карбыз түгел, эчен ярып карап булмый. Безнекеләр юкка, бер дә тикмәгә кулга алмаслар...

— Борыл, уңга!

Кырыс әмер уйларымны бүлдерде. Мин ялгыз гына түгел, өчәү барабыз икән ләбаса.

Толстой тыкрыгыннан борылып, безнең тулай торак шушында, Карл Маркс урамына чыктык. Монда бупбуш, машиналар да күренми. Әле трамвайлар да шалдыршолдыр йөри башламаган. Кала өчен сәер бер тынлык. Асфальт түшәлгән киң урамның ике ягы буйлап тезелгән өчәр, дүртәр катлы ташпулатларның тәрәзәләрендә пәрдәләр. Йоклыйлар. Иртәнге тәмле төшләрен күрәкүрә йоклыйлар булыр бу йортлардагы казанлылар.

— Шарт-шорт!

— Шарт-шорт!

Эңгер-меңгердә йокымсырап торган урам, сискәнепсискәнеп, безнең өч пар дагалы итекнең шакылдавын кабатлый:

— Шарт-шорт!

— Шарт-шорт!

Уң ягымдагы опервәкил (ул үзен шулай таныштырды) буйга миннән аз гына калку, гәүдәгә дә тулырак. Күкрәге киерелеп алга чыккан. Башы югары күтәрелгән — парадта Мавзолей яныннан узамыни. Бик тырышып кырынган булуына да карамастан, сакал-мыеклары күгәреп тора. Борыны бөкре. Кашлары кап-кара, бергә кушылып, эчкә баткан ачулы күзләрен каплап торалар. Зәһәр, усал күренә, сөйләшми. Янындагы яшьрәк егеткә боерыкны кашлары белән генә бирә; аларны бер төшерә, бер күтәрә, янәсе, алып кал, алып кит минем